ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясына үзгәреш кертү турында» 26-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясына үзгәреш кертү турында» 26-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 147-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясына үзгәреш кертү турында

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясының 5 пунктындагы икенче абзацына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш),№ 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), икенче җөмләгә «Тукай муниципаль районы» сүзләре алдыннан «Әгерҗе муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Сарман муниципаль районы,» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында өч һәм аннан артыграк балалары булган гражданнарга (алга таба – күп балалы гаиләләр) җир кишәрлекләре бирү белән бәйле вәзгыять күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү вариантларын киңәйтү кирәклеген күрсәтә.

Башлангыч чорда җир кишәрлекләре дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге буш җирләрдән бирелгән. Шулай ук федераль милектәге җир кишәрлекләре дә сатылган. Хәзерге вакытта шәһәр округларында әлеге категория гражданнарны бирү өчен җир кишәрлекләре җитмәү белән бәйле проблема бар.

Күп балалы гаиләләргә бирү өчен буш җир кишәрлекләре булмау проблемасын хәл итүнең бер варианты булып күп балалы гаиләләргә башка муниципаль берәмлектә җир кишәрлеге алу хокукын бирү тора. 2024 елның 14 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясына үзгәрешләр кертелде, аның нигезендә шәһәр округларында даими яшәүче күп балалы гаиләләргә тиешле шәһәр округы милкендә булган яисә алар белән идарә итү һәм аларны бирү вәкаләтләре Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган, республиканың башка муниципаль районнарында:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче гражданнарга Югары Ослан, Биектау, Зеленодольск, Лаеш, Питрәч муниципаль районнары чикләрендә;

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче гражданнарга Тукай муниципаль районы чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен бирергә мөмкин.

Шуның белән бергә, Чаллы шәһәре мэры мәгълүматы буенча, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә 6 035 күп балалы гаилә җир кишәрлекләре белән тәэмин ителмәгән, һәм аларны тәэмин итү өчен кирәкле 900 гектардан да ким булмаган җирләр шәһәр округы чикләрендә юк.

Моңа бәйле рәвештә закон проектында «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими яшәүче күп балалы гаиләләргә Тукай районыннан тыш тагын 8 якын-тирә муниципаль районда: Әгерҗе, Актаныш, Алабуга, Зәй, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим һәм Сарман районнарында урнашкан җир кишәрлекләрен бирү мөмкинлеге карала.

Законны кабул итү 6 меңнән артык күп балалы гаиләне җир кишәрлекләре белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

# Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә 2024 елның 27 сентябренә күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү барышы турында мәгълүмат

| №<br>п/п | Муниципаль берәмлек исеме | Бирелгән гаризалар саны | Исемлеккә кертелгәннәр саны | Кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре саны | Аларны бирү турында карар кабул ителгән җир кишәрлекләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | саны | мәйданы, га |
| 1 | Әгерҗе | 631 | 631 | 636 | 631 | 63,100 |
| 2 | Азнакай | 1248 | 1154 | 1272 | 1121 | 100,880 |
| 3 | Аксубай | 330 | 328 | 383 | 328 | 45,744 |
| 4 | Актаныш | 703 | 621 | 764 | 572 | 78,598 |
| 5 | Алексеевск | 653 | 651 | 701 | 633 | 74,996 |
| 6 | Әлки | 195 | 190 | 350 | 190 | 23,675 |
| 7 | Әлмәт | 4361 | 4351 | 2895 | 2823 | 226,236 |
| 8 | Апас | 318 | 318 | 330 | 316 | 37,079 |
| 9 | Арча | 1599 | 1542 | 1254 | 1244 | 120,130 |
| 10 | Әтнә | 306 | 306 | 324 | 301 | 37,272 |
| 11 | Баулы | 800 | 798 | 828 | 789 | 103,633 |
| 12 | Балтач | 872 | 870 | 834 | 799 | 117,280 |
| 13 | Бөгелмә | 1408 | 1312 | 920 | 876 | 96,715 |
| 14 | Буа | 882 | 880 | 839 | 746 | 78,807 |
| 15 | Югары Ослан | 480 | 476 | 542 | 471 | 68,030 |
| 16 | Биектау | 1350 | 1341 | 1019 | 943 | 93,522 |
| 17 | Чүпрәле | 355 | 353 | 396 | 350 | 67,420 |
| 18 | Алабуга | 2158 | 2152 | 1950 | 1949 | 260,062 |
| 19 | Зәй | 1015 | 1015 | 975 | 885 | 107,988 |
| 20 | Зеленодольск | 2864 | 2860 | 2137 | 2011 | 146,522 |
| 21 | Казан шәһ. - шәһәр округы | 23933 | 18125 | 8291 | 7466 | 485,420 |
| 22 | Кайбыч | 326 | 326 | 363 | 325 | 47,958 |
| 23 | Кама Тамагы | 301 | 301 | 334 | 300 | 38,861 |
| 24 | Кукмара | 1771 | 1769 | 1022 | 1014 | 127,580 |
| 25 | Лаеш | 1600 | 1586 | 1361 | 1260 | 126,120 |
| 26 | Лениногорск | 1074 | 1074 | 752 | 744 | 105,573 |
| 27 | Мамадыш | 1046 | 918 | 1030 | 910 | 117,463 |
| 28 | Менделеевск | 726 | 724 | 771 | 721 | 84,906 |
| 29 | Минзәлә | 815 | 815 | 837 | 812 | 91,203 |
| 30 | Мөслим | 598 | 597 | 644 | 556 | 68,534 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 31 | Чаллы шәһ. - шәһәр округы | 9434 | 9429 | 3404 | 3399 | 263,304 |
| 32 | Түбән Кама | 4576 | 4573 | 3909 | 3705 | 397,000 |
| 33 | Яңа Чишмә | 265 | 265 | 292 | 265 | 46,450 |
| 34 | Нурлат | 1016 | 1015 | 1063 | 1014 | 100,669 |
| 35 | Питрәч | 1401 | 1395 | 1448 | 1384 | 162,041 |
| 36 | Балык Бистәсе | 353 | 340 | 391 | 333 | 55,380 |
| 37 | Саба | 1142 | 1141 | 1162 | 1142 | 110,915 |
| 38 | Сарман | 1023 | 1020 | 1119 | 1019 | 127,106 |
| 39 | Спас | 324 | 320 | 329 | 320 | 38,731 |
| 40 | Тәтеш | 360 | 349 | 359 | 341 | 41,800 |
| 41 | Тукай | 1403 | 1363 | 1365 | 1246 | 168,225 |
| 42 | Теләче | 420 | 420 | 500 | 420 | 58,451 |
| 43 | Чирмешән | 169 | 166 | 216 | 166 | 18,680 |
| 44 | Чистай | 1575 | 1573 | 1676 | 1554 | 132,406 |
| 45 | Ютазы | 461 | 460 | 495 | 460 | 41,29 |
| | **Барлыгы:** | **78640** | **72213** | **52482** | **48854** | **5003,755** |

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының өч һәм аннан күбрәк баласы булган, шәһәр округлары территориясендә даими яшәүче гражданнарга алар белән идарә итү һәм аларны бирү Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләрен бергәндә үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» 2016 елның 30 сентябрендәге 696 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының**
**32$^{1}$ статьясына үзгәреш кертү турында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32$^{1}$ статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларының һәм Татарстан Республикасы бюджетының чыгымнары артуны кире какмый, шул исәптән күрсәтелгән җир кишәрлекләрен күләмен бәяләү мөмкин булмаган кирәкле инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү өлешендә дә.